Мәктәп туры

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
ҖАВАПЛАРЫ

(2024-2025 нче уку елы)
6 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут
Максималь балл – 30

1. Мәзәкләр турында исеңә төшер. Аларны кайчан сөйлиләр? Мәзәкләр турында белгәннәреңне яз. (5 балл)

Җавап: Мәзәк – халык авыз иҗаты әсәре. Аны күңел күтәрү максаты белән сөйлиләр. Ул кыскалыкка, юмор-сатирага, көтелмәгән бетемгә йөз тоткан, төгәлләнгән сюжетка корылган иң кечкенә эпик жанр. Мәзәк юмористик эчтәлеккә нигезләнә.

2. Рәсемне кара. Ул кайсы әсәргә ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз. Геройларын ата. (5 балл)

Җавап: Габдулла Тукай. «Су анасы».

Әсәр геройлары: малай, Су анасы, әни.

3. Фәнис Яруллин әсәрен билгелә. (1 балл)

а) «Яз башы»

ә) «Зәңгәр күлдә Ай коена»

б) «Чыбыркы»

в) «Патша белән карт»

<u>Җавап:</u> ә) «Зәңгәр күлдә Ай коена»

4. **Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән төп хис-кичерешне билгелә. (5 балл)**

– «Сез кайсы халыктан?» — дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе…
Тан булып нур сибә Ватаным.

<u>Җавап</u>: Разил Вәлиев. «Ватаным».

Хис-кичереш – туган ил белән горурлану, аның батырларына, кешеләренә соклану.

5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу шәхес турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)

1) _____

2) _____

3) _____

<u>Җавап:</u>

1) К. Насыйри 1825 елның 14 нче февралендә Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылында туа.

2) 1871 елда Казанда үз мәктәбен оештыра, монда татар балаларына рус телен укыта.

3) К. Насыйринең «Әбүгалисина», «Кырык бакча», «Кырык вәзир» h.б. әсәрләре бар h.б.

6. Чит илне макта, үз илендә яшә, диләр. Бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (8 балл)